**“Г.И. Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы” ДАҺБУ**

Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгының күп өлкәләренә белгечләр әзерли торган иң зур, иң танылган уку йортларының берсе - “Г.И. Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы” үзенең 100 еллыгын билгеләп үтте. Бу аз гомер түгел. Әмма агросәнәгать комплексы системасы өчен кадрлар әзерләүче бу белем йорты бер дә картаймый, һәрвакыт яшь. Техникумда яшьләр укыганлыктан, анда һәрвакыт яшьлек рухы хөкем сөрә.



1917 елда, Октябрь революциясеннән соң ук, Змиеводагы алпавыт утарларының берсендә тәҗрибә хуҗалыгы оештырыла, аның белән Владимир Данилович Каблуков җитәкчелек итә. Хуҗалык базасында 1919 елда Чистай өязе крестьяннары балаларын укыту өчен бер еллык авыл хуҗалыгы мәктәбе ачыла. 1920 елда агротехника мәктәбенең беренче чыгарылышы була. Анда ул вакытта эшчеләр һәм техниклар укыта.

Егерменче ел. Илдә гражданнар сугышы бара. Әмма шундый катлаулы елларда да совет хөкүмәте Россиядә һөнәри – техник уку йортлары челтәре оештыру турында карар кабул итә.

1920 елда провинциаль Кама аръягы төбәгендә авыл хуҗалыгы техникумы оештырыла, техникумга, нигездә, әле шинельләрен һәм буденовкаларын салырга да өлгермәгән солдатлар укырга килә. Аның уку классларын Чистайның элеккеге сәүдәгәре Е.И.Чукашов утарына (К.Маркс урамы, 23) күчерелә, әлеге бина унтугызынчы гасырның беренче яртысында төзелгән була. Студентлар өйрәнү мастерскойларына Ленин урамындагы бинага йөриләр, ул мастерскойлар хәзер дә шунда. Техникумда укучылар Ленин урамындагы 2 һәм К.Маркс урамындагы 17 нче йортларда ачылган тулай торакларда яшиләр.

Кызганычка каршы, шәһәр һәм республика архивларында авыл хуҗалыгы техникумы ачылуның төгәл көне билгеләнмәгән.

Чистай авыл хуҗалыгы техникумында беренче чыгарылыш 1923 елда була. Ул елны 11 кеше агроном-кырчы дипломы алып чыга.

Авыл хуҗалыгы производствосын индустриальләштерү өчен техник яктан белемле кадрлар кирәк була, менә шуңа күрә дә 1930 елда авыл хуҗалыгын механикалаштыру бүлеге ачыла, ә 3 елдан инде ул 34 техник-механик әзерләп чыгара. Шуннан бирле “Авыл хуҗалыгын механикалаштыру” белгечлеге уку йортының төп юнәлешен билгеләүче белгечлек булып санала.

1936 елда техникумга югары белемле инженер-механик, Ленинград авыл хуҗалыгы институты дипломы алган Харис Кәбирович Басыйров килә. Ул техникум директорының укыту буенча урынбасары итеп билгеләнә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, техникумда укулар туктала. Укытучыларның бер өлеше һәм укучыларның күбесе фронтка китә. 1942 нче

елның көзендә уку бинасын, тулай торакны һәм ашханәне Чистайга эвакуацияләнгән Икенче Мәскәү сәгать заводына бирәләр, ә җиһазларны өйрәнү мастерскойлары биналарына күчерәләр.

1942 нче елның җәендә Татарстанның игенчелек буенча халык комиссары укытучы - агроном Гыйльметдин Шәрәфетдинович Заһировны техникумга чакыра һәм эшне яңартып җибәрергә тәгъдим итә. Дәресләр югарыда әйтеп үтелгән мастерскойларда башланып китә.


Здание Чистопольского техникума механизации сельского хозяйства по ул. К.Маркса, д.78
1944-1985 гг.

Укыту өчен шартлар кысынкырак булса да, 1944 нче елда агрономнар әзерләү бүлеге эшли башлый. Шул ук елны техникум К. Маркс урамындагы 78 нче йортка күчә.

Урта буын белгечләре җитмәү сәбәпле, читтән торып уку бүлеге ачуга ихтыяҗ туа, ул 1960 елда ачыла һәм уку йортының алга таба үсешенә зур йогынты ясый, үз нәтиҗәләрен бирә. Техникумның матди-техник базасы киңәя, эш шартлары яхшыра, инструментлар, техника сатып алына.

1970 нче елда авыл хуҗалыгын механикалаштыру техникумы В.И.Чапаев исемендәге колхоз белән берләштерелә һәм совхоз-техникум итеп үзгәртелә.

Илебездәге авыл хуҗалыгын үстерүнең мөһим проблемалары югары сыйфатлы терлекчелек продукциясе бирергә сәләтле белгечләр әзерләү бурычын куя. Нәкъ менә шул сәбәпле 1988 елда совхоз – техникумда яңа белгечлек барлыкка килә, бу – авыл хуҗалыгы производствосында технолог – оештыручы. Элеге бүлекне тәмамчылауларның төп бурычы – үсемлекчелектәге һәм терлекчелектәге эшләрнең тормышына икътисадый анализ ясау.

70-80-нче елларда илгә яңа кадрлар кирәк булганда, дәүләт халык хуҗалыгын механикалаштыру, автоматлаштыру, электрлаштыру буенча бик мөһим проектларны тормышка ашыра, аларда авыл хуҗалыгы техникумы актив катнаша.

1985 нче елда, яңа укыту чаралары белән җиһазландырылып, техникумның яңа уку коплексы ачыла. Биредә ике уку-укыту корпусы, спорт залы, махсус остаханәләр, гараж, актлар залы, ашханә, тулай торак төзелә.

Еллар узу белән уку йортын үстерү өчен бик күп эшләр эшләнә. Техникумның укыту – лаборатория базасы үзгәрә, киңәя һәм ныгый.

Җир мөнәсәбәтләрен реформалаштыру, җир кишәрлегенең төрле формаларын формалаштыру чорында, җир белән идарә итү өлкәсендә квалификацияле кадрлар җитмәү сәбәпле, 1991 елда "Җир төзелеше" бүлеге ачыла.

Халык хуҗалыгы масштаблары үсү шартларында, икътисадый анализ, мәгълүматны компьютер эшкәртү, финанс, кредит, статистика, җитештерүчәнлекне планлаштыру һәм оештыру принципларын камилләштерү максатында, 1998 елда "Икътисад, бухгалтерлык исәбе һәм контроль" бүлеге ачыла.

Хәзерге вакытта авыл хуҗалыгы техникумы агросәнәгать комплексы өчен биш белгечлек буенча кадрлар әзерләп чыгара. Менә шул белгечләрне әзерләүдә Чистай авыл хуҗалыгы техникумының республикада тоткан урыны аеруча саллы. Техникум үзенең укучылары өчен тормыш мәктәбе дә булып тора.



**БЕЛГЕЧЛЕКЛӘР АЧЫЛУ ТАРИХЫ:**

- 1930 елда «Авыл хуҗалыгын механикалаштыру " бүлеге ачыла.
- 1967 елда «Авыл хуҗалыгын электрлаштыру һәм автоматлаштыру" бүлеге ачыла.
- 1988 елда «Авыл хуҗалыгы җитештерүен технолог-оештыручы" бүлеге ачыла.
- 1991 елда "Җир төзелеше" бүлеге ачыла.
- 1997 елда «Хокук белеме " бүлеге ачыла.
- 1998 елда "Икътисад, бухгалтерлык исәбе һәм контроль" бүлеге ачыла.
- 2017 елда «Компьютер системаларын программалаштыру», «Банк эше», «Дизайн (тармаклар буенча)» белгечлекләре лицензияләнә.

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 05.11.2001 елның 2029 боерыгы нигезендә "Чистай" совхоз-техникумы «Чистай авыл хуҗалыгы техникумы» урта һөнәри белем бирү федераль дәүләт мәгариф учреждениесе дип үзгәртелә.

Россия Федерациясенең 31.12.2004 ел, № 1768-р күрсәтмәсе нигезендә «Чистай авыл хуҗалыгы техникумы» урта һөнәри белем бирү федераль дәүләт мәгариф учреждениесе» Чистай авыл хуҗалыгы техникумы" урта һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениесе дип үзгәртелә.

21.04.2008 елдан башлап, Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 21.08.2008 ел, № 04/1-39-боерыгы нигезендә «Чистай авыл хуҗалыгы техникумы» урта һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениесе «Чистай авыл хуҗалыгы техникумы» дип үзгәртелә.

25.11.2014 елдан, ТР Министрлар кабинетының № 910 карары нигезендә, “Чистай авыл хуҗалыгы техникумы” урта һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе “Г.И. Усманов исемендәге Чистай авыл хуҗалыгы техникумы” дип үзгәртелде.